КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 декабрь г.Казань № 1167

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү чараларын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указын алга таба тормышка ашыру, юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10ысына кадәр, Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе секретариатына бу карар белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру турында хисап кертүне;

халык арасында фотога һәм видеога автомат рәвештә төшерү системаларын файдаланып чыгарылган административ хокук бозулар турындагы эшләрнең карарлары күчермәләрен Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алу буенча хезмәт күрсәтүне популярлаштыру эшен оештыруны.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2020 елның 1 мартына кадәр, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, автомобиль юлларының куркыныч авария участокларын, юл-транспорт һәлакәтләренең еш була торган потенциаль урыннарын һәм һәлак булучылар белән берәр юл-транспорт һәлакәтләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләүне һәм 2020 елның 1 июленә кадәр аларны бетерү буенча планлаштырылган чараларны тормышка ашыруны тәэмин итүне;

2020 елның 1 июненә кадәр федераль әһәмияттәге автомобиль юлларындагы, төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларының терәк челтәрендәге юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Зебра» билгесен) яңартып бетерүне һәм 2020 елның 15 июленә кадәр юл участокларының калган өлешләрендә яңартып бетерүне;

2020 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкаруны;

автомобиль юлларын капиталь ремонтлауга һәм реконструкцияләүгә проект документларын эшләгәндә «2+1» принцибы буенча өч полосалы бер-бер артлы хәрәкәт итүне, шулай ук, юл өчен бүлеп бирелгән җитәрлек киңлектәге полосасы булган участокларда каршы килә торган транспорт агымнарын аерып, «2+2» принцибы буенча дүрт полосалы хәрәкәт итүне оештыру мөмкинлеген карап тикшерүне;

түбәндәгеләрне дәвам итүне:

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларында, беренче чиратта, белем бирү оешмалары, җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары, автобус тукталышлары янында, автомобиль юлларының куркыныч авария участокларында һәм халык күпләп җыела торган урыннарда ясалма яктырткычны төзекләндерүне;

светодиодлы индикациясе булган 5.19.1 һәм 5.19.2 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны» юл билгеләрен урнаштыру эшләрен;

«тамчы» тибындагы кырый һәм үзәк билгесен куллану практикасын;

җәяүлеләр юл аша җир өстеннән чыгу урыннарына, юл чатларына килгән җирләрдә һәм автомобиль юлларының авария хәлендәге участокларында аркылы һәм буйлы тавыш полосаларын урнаштыруны;

төзелеп, реконструкцияләп, капиталь ремонт яки ремонт ясалып беткәннән соң кулланышка кертелә торган автомобиль юллары участокларының һәм юл корылмаларының юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килү-килмәвен алдан бәяләгәндә тиешле комиссияләрнең составына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына караган Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең вазыйфаи затларын (килешү буенча) кертүне;

каршы килә торган хәрәкәт полосасына чыгу аркасында барлыкка килә торган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү өчен, шулай ук җәяүлеләрнең юлны чыгу өчен каралмаган урыннарда машиналар йөри торган өлештән чыгуын чикләү өчен барьер тибындагы металл киртәләр һәм җәяүлеләр киртәләрен куюны дәвам итүне;

автомобиль юллары участокларына реконструкция һәм ремонт ясала торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш полосаларын, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына караган Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең патруль автомобильләре макетларын, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога

һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллануга юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашыруны;

ведомство карамагындагы автомобиль юллары участокларында, транспорт агымының туктаусыз хәрәкәтен, шул исәптән машина юлларыннан транспорт чараларына үтәргә комачаулый торган объектларны алуны тәэмин итеп, юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерү буенча чаралар күрүне;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә:

2020 елның 1 июненә кадәр юл хәрәкәтен оештыру проектларына юл хәрәкәтен оештыруның милли стандартлар белән каралган техник чараларын (1.24.4 юл билгесе, 8.23 «Фотога һәм видеога төшерү» табличкасы) кертүне һәм 2020 елның 1 сентябренә кадәр аларны урам-юл челтәрендә проект документлары нигезендә куллануны тәэмин итүне;

юл хәрәкәтендә катнашучыларга Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны автомат рәвештә фотога һәм видеога төшерүнең автомат режимында эшли торган техник чаралары урнашкан урыннар һәм аларның географик координатлары күрсәтелгән геопозицияләре турында һәркем өчен файдалана алу мөмкинлеге булган мәгълүмат ресурслары ярдәмендә хәбәр итүне тәэмин итүне.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2020 елның 1 августына кадәр тизлекне мәҗбүри рәвештә киметү чараларын, шул исәптән җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары белән янәшә булган ясалма тигезсезлекләрне урнаштыру планын тормышка ашырырга;

«Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проектының «Юл челтәре» проектының төбәк өлеше булган юл эшчәнлеге программаларын формалаштырганда төбәк әһәмиятендәге, шулай ук Казан, Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәр агломерацияләре автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген арттыруга юнәлдерелгән инженерлык чараларын күздә тотарга;

көн саен мәктәп автобусларын эксплуатацияләү мониторингын үткәрергә һәм кызыксынучы министрлыкларга һәм ведомстволарга алардан файдалана алу мөмкинлеге торышы, тизлек режимын саклавы турында мәгълүмат бирергә;

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксилар белән пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга заказлар кабул итүне һәм (яки) тапшыруны гамәлгә ашыручы компанияләр һәм пассажир йөртүчеләрнең үзләре белән мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү төзү мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә һәм аның кысаларында такси эшчәнлегенә һәм тиешле тәртиптә җиһазландырылган транспорт чараларына рөхсәт кәгазе булган затларга гына заявкалар тапшыруны гамәлгә ашырырга;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, 2020 елның 20 мартына кадәр муниципаль юл фондлары акчасының үзләштерелми калган өлешен 2020 елда юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча беренчел чираттагы чараларны башкаруга җибәрү турындагы тәкъдимнәрне, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, 2020 елга юл эшләре программаларын баш-

кару кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары үтә торган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының техник һәм эксплуатацияләү күрсәткечләрен арттыру чараларын тормышка ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

ата-аналарны балаларның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларын кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик рейдларга, олылар белән балаларны имин йөртү кагыйдәләре буенча аңлату эшләренә җәлеп итеп, ата-аналар патрульләре эшчәнлеген оештыруны тәкъдим итәргә;

белем бирү оешмалары эшчәнлегендә «www.sakla.ru» порталында урнаштырылган мәгълүмати материалларны куллануны оештырырга;

яшь хәрәкәт инспекторларының матбугат үзәкләре эшен оештыру өчен өстәмә белем бирү педагоглары ставкаларын билгеләү мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә;

соңгы дәресләрдә «куркынычсызлык минутлары»ын үткәрүне, шулай ук балаларга һәм ата-аналарга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту темасы буенча белем бирүгә, шул исәптән аларның киемендә яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм балаларны тотып тора торган җайланмаларны һәм куркынычсызлык каешларын файдалануга юнәлдерелгән чаралар (дәресләр, әңгәмәләр һәм инструктажлар) үткәрүне дәвам итәргә;

түбәндәгеләр белән:

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының яшь хәрәкәт инспекторлары матбугат үзәкләренең журналистлар корпусына керүче яшь хәрәкәт инспекторларына методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә:

яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядларының республика форумын үткәрергә;

2019/2020 уку елы дәвамында белем бирү оешмаларында яшь хәрәкәт инспекторлары эшчәнлеген оештыруга һәм балигъ булмаганнарга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүгә тикшерү үткәрергә;

җәйге каникул чорында «Дзержинец» балалар сәламәтләндерү лагеры базасында яшь хәрәкәт инспекторлары конкурсының район этабы призерларының юнәлешле сменасын оештырырга;

Татарстан Республикасының «Тормыш эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә:

яшь хәрәкәт инспекторлары отрядлары җитәкчеләре өчен квалификация күтәрү курсларын оештырырга;

укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең «Мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балаларга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» программасы буенча белем алуын дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, ярты елга кимендә бер тапкыр транспорт чарасы белән идарә итү стажы кимендә ике ел булган машина йөртүчеләр тарафыннан кылынган, һәлак булучылары булган юл-транспорт һәлакәтләрен анализларга, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр утырышларында белем бирү

сыйфаты түбән булган автомәктәп җитәкчеләренә алга таба тыңлау өчен аларның кылыну сәбәпләрен ачыкларга;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә:

яшь хәрәкәт инспекторлары отрядлары эшчәнлеген үстерү белән шөгыльләнүче педагогларны финанслар белән тәэмин итү мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә;

республиканың барлык муниципаль районнарындагы балалар лагерьларында яшь хәрәкәт инспекторларының юнәлешле сменаларын оештырырга;

көндәлек тикшерүне оештырырга:

мәктәп автобуслары белән балаларны оешкан рәвештә йөртү, шул исәптән «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган тахограф һәм борттагы навигация җайланмалары эшләве кагыйдәләрен саклауны;

балаларның Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә һәм балалар хәрәкәтенең куркынычсыз маршрут схемалары нигезендә хәрәкәт итүен;

укучыларының яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм ата-аналар җыелышларында һәм сыйныф сәгатьләрендә аларны куллану кирәклеге турында искәртүне.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына яшьләр оешмаларын һәм берләшмәләрен юл-транспортта имгәнүләрне кисәтү, шул исәптән пропаганда чаралары кысаларында, махсуслаштырылган акцияләр һәм семинарлар эшенә җәлеп итүне активлаштырырга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, балаларның һәм яшүсмерләрнең массакүләм ял итү вакытында, шул исәптән балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмаларында балаларның юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү буенча профилактик белем бирү чараларын (тематик кичәләр, уеннар, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнү, юлларда үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләренә интерактив өйрәтү) үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына республикада тренерлар һәм җитәкчеләр өчен өстәмә ставкалар бирүне, шулай ук карт-клубларны матди-техник тәэмин итүне үз өченә алган картинг спортын үстерү өчен шартлар тудыру мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә.

7. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, 1 елга кимендә дүрт тапкыр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын җәлеп итеп, юл-транспорт һәлакәтләренә карата чара күрү буенча тактик-махсус өйрәнүләр үткәрергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, белем бирү оешмаларын максималь җәлеп итеп, «Тормыш иминлеге өчен юлларда куркынычсызлык» темасына тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре буенча дәрес үткәрергә;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, һава шартлары начараю

һәм СМС-хәбәр итү юлы белән гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның оператив фаразы турында халыкка хәбәр итү буенча кәрәзле элемтә операторлары белән эшне дәвам итәргә;

юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерүгә җәлеп ителә торган көчләр һәм чаралар үз вакытында әзер булу һәм оператив чара күрү максатларында, Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүнең оператив фаразын кызыксынучы министрлыкларга һәм ведомстволарга көн саен тапшыруны оештырырга.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

«Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүне үстерү» программасы кысаларында «Татарстан Республикасында, санитария авиациясен кулланып, ашыгыч медицина ярдәменең үз вакытында күрсәтүен тәэмин итү» ярдәмче программасын нәтиҗәле тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының транспорт чаралары йөртүчеләрдә (транспорт чаралары йөртүчеләргә кандидатларда) медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр, медицина күрсәткечләре яки транспорт чаралары белән идарә итүгә билгеләнгән тәртип нигезендә медицина чикләүләре булуы (булмавы) турында медицина бәяләмәсенең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару эшен оештырырга.

9. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм кызыксынучы затлар белән утның күчмә чыганагын (фонарь) һәм өлкән яшьтәге халык өчен яктылыкны кире кайтару элементлары булган әйберләрне реализацияләү мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә.

10. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, экологик икеайлыклар чорларында Татарстан Республикасында юл сервисы объектлары, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосалары һәм юл буе полосаларының санитария-экология торышын тикшерүдә тоту эшен оештырырга.

11. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы белән күздә тотылган җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү чараларын Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү буенча адреслы исемлегенә бары 2020 елда алар тарафыннан әлеге ярдәмче программаның шундый ук конкрет чараларын тигез финанслашу шарты белән генә кертергә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән берлектә, Татарстан Республикасының муниципаль һәм җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү максатла-

рында транспорт чараларының авырлык үлчәү контроле эшен оештыру буенча пилот проектын эшләргә.

12. Татарстан Республикасының «Тормыш эшчәнлеге иминлегенең фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең «Мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балаларга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» программасы буенча белем алуын дәвам итәргә;

2020 елның 1 июленә кадәр, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең низаг китереп чыгарырга омтылучы блогерлар һәм юл хәрәкәтендә катнашучылар белән аралашкандагы гамәлләргә карата квалификациясен күтәрү курсларын оештырырга.

13. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

яктылыкны кире кайтару элементларын, шул исәптән утның күчмә чыганагын (фонарь) куллану кирәклеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга;

массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеге буенча түбәндәге социаль рекламаны даими нигездә урнаштырырга:

җәяүлеләр катнашында балалар юл-транспорт имгәнүләрен һәм юл-транспорт һәлакәтләрен киметүгә юнәлдерелгән;

исерек хәлдә транспорт чарасы белән идарә итү фактлары һәм мондый фактларның фаҗигалы нәтиҗәләре турында;

юл-транспорт һәлакәтләрен евроберкетмә ярдәмендә рәсмиләштерүне популярлаштыру турында.

14. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенә, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авырлык үлчәү контролен үстерү страте-гиясен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1181 нче карары белән расланган 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авырлык үлчәү контролен үстерү стратегиясе нигезендә автоматлаштырылган системаларны кулланышка кертүне дәвам итәргә.

15. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына:

Татарстан Республикасының муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия утырышларын әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашуны дәвам итәргә;

муниципаль берәмлекләр тарафыннан юл-транспорт һәлакәтләренең еш була торган урыннарын, автомобиль юлларының потенциаль һәлакәт участокларын һәм һәлак булучылар белән берәр юл-транспорт һәлакәтләре булган юл участокларын бетерү буенча күздә тотылган чараларны, шулай ук муниципаль юл фондлары акчасының калган өлеше исәбеннән үтәлеше планлаштырылган чараларны килештерүдә һәм тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашырга;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, перинаталь үзәкләрдә һәм бала табу йортларында балаларның юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау буенча, шул исәптән балаларны имин йөртүне тәэмин итү буенча ата-аналар белән уку-укыту тренингларын үткәрүне оештырырга;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, квартал саен «Юл бир» дигән профилактик чара үткәрергә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән берлектә, түбәндәгеләрне эшләү турындагы мәсьәләне карап тикшерергә:

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексына транспорт чарасы белән идарә итүче (милекче) тарафыннан Юл хәрәкәте кагыйдәләрен системалы рәвештә бозган өчен административ җаваплылыкны күздә тота торган аерым статья кертүне;

компанияләргә, аккаунттан файдаланучының транспорт чарасы белән идарә итү хокукы булмаган яки мондый хокуктан мәхрүм ителгән затларга тапшырган өчен административ җаваплылыгын билгеләп, аккаунт бирүне компетентлы органнар белән килештерүне, шулай ук сервис хуҗасының әлеге категориядәге затларга аккаунтны биргән һәм транспорт чарасы белән идарә итүне тапшырган өчен җаваплылыгын тиңләштерүне йөкләп, автомобильләрне кыска вакытлы арендалау буенча хезмәтләр күрсәтүне федераль законнар белән хокукый җайга салуны;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә:

җәяүлеләрнең юл аша җир өстеннән чыгу урыннарына, юл чатларына якынаю урыннарына һәм автомобиль юлларының аварияле участокларына аркылы тавыш полосаларын һәм транспорт чаралары әйләнеп каплануын булдырмау максатларында машина юлы кырые буйлап буйлы тавыш полосаларын урнаштыруны дәвам итәргә;

юл хәрәкәтен оештыруга үзгәреш кертүне күздә тота торган проект документларын раслаганда тиешле проектларны һәм схемаларны Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә килештерүгә кертүне тәэмин итәргә;

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексының 20.25 статьясындагы 1 өлеше буенча административ эшләрне карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә суд органнары тарафыннан салынган административ штрафларны түләтү эшен активлаштырырга;

мәҗбүри эшләр рәвешендәге суд карарларының тиешле үтәлешен тикшерүдә тотуны оештырырга һәм Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар

турындагы кодексының 20.25 статьясындагы 4 өлеше буенча мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәүдән баш тартучы затларны административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә;

үтәтү производстволары кысаларында арест салынган транспорт чараларын күчерүне һәм саклауны оештыру өчен шартнамә төзү мөмкинлеген карап тикшерергә, шулай ук җаваплы саклаудагы арест салынган мөлкәтне файдаланган өчен затларны административ җаваплылыкка тарту эшен активлаштырырга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, штрафлары 10 мең сумнан артып киткән бурычлыларга карата транспорт чаралары белән идарә итү хокукын чикләү эшен активлаштырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына:

гражданнар җыеннарында яктылыкны кире кайтару элементларын, шул исәптән утның күчмә чыганагын (фонарь) куллану кирәклеге турында аңлату эшләрен үткәрергә;

муниципаль юл фондлары акчасының калган өлешләрен файдалану кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар исемлеген әзерләгәндә, беренче чиратта, балалар белем бирү оешмалары (мәктәпләр һәм балалар бакчалары) һәм халык күпләп җыела торган объектлар янында урам-юл челтәрен төзекләндерүне, шулай ук җәяүлеләрнең җайга салынмый торган юл аша чыгу урыннары белән янәшә ясалма тигезсезлекләр урнаштыруны күздә тотарга;

2020 елның 1 февраленә кадәр:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль бүлекчәләре белән берлектә, юл-транспорт һәлакәтләренең еш була торган урыннарын, автомобиль юлларының куркыныч авария участокларын һәм һәлак булучылары белән берәр юл-транспорт һәлакәтләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләргә;

тизлекне мәҗбүри рәвештә киметү (шул исәптән җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары белән янәшәдәге) чараларын урнаштыру планын Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә кертергә һәм 2020 елның 1 августына кадәр план чараларын тормышка ашырырга;

2020 елның 1 июненә кадәр юл хәрәкәтен оештыру проектларына юл хәрәкәтен оештыруның милли стандартлар белән күздә тотылган техник чараларын (1.24.4 юл билгесе, 8.23 «Фотога һәм видеога теркәү» табличкасы) кертергә һәм 2020 елның 1 сентябренә кадәр аларны урам-юл челтәрендә проект документлары нигезендә куллануны тәэмин итәргә;

юл хәрәкәтендә катнашучыларга Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны автомат рәвештә фотога һәм видеога төшерүнең автомат режимында эшли торган техник чаралары урнашкан урыннары һәм аларның географик координатлары күрсәтелгән геопозицияләре турында һәркем өчен файдалана алырлык мәгълүмат ресурслары ярдәмендә хәбәр итүне тәэмин итәргә;

2020 елның 15 июленә кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында (шул исәптән 1.14.1 «Зебра» билгесен) яңартып бетерергә;

2020 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Зебра» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкарырга;

2020 елның 1 июленә кадәр автомобиль юлларының куркыныч авария участокларын, юл-транспорт һәлакәтләренең еш була торган потенциаль урыннарын һәм һәлак булучылар белән берәр юл-транспорт һәлакәтләре булган юллар участокларын бетерү эшләрен төгәлләргә;

2020 елның 10 декабренә кадәр 2021 елда муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзергә;

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә урам-юл челтәрен карап тотуга (юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын карап тотуны, юлдагы чокырларга ремонт үткәрү һәм юл билгеләрен төшерүне кертеп) озак вакытка исәпләнгән муниципаль контрактлар төзү мөмкинлеген (расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу вакытларын исәпкә алып) карап тикшерергә;

бюджетларда балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуын тәэмин итүгә, транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерүгә, юл хәрәкәте иминлеген пропагандалауга һәм автомобиль юлларының куркыныч авария участокларын бетерүгә юнәлдерелгән юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программалар чараларын тормышка ашыруга чыгымнарны күздә тотарга;

җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү эшләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы акчасы исәбеннән финансланганда 2020 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программаларда җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын төзекләндерү буенча шундый ук чыгымнарны җирле бюджет акчасы исәбеннән күздә тотарга;

җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын норматив таләпләргә туры китерү эшен дәвам итәргә, шул ук вакытта светодиодлы индексациясе булган 5.19.1 – 5.19.2 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны» юл билгеләрен урнаштыруны күздә тотарга;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне укуга әзерләү кысаларында гомуми белем бирү оешмаларында беренче сыйныф укучыларын яктылыкны кире кайтару элементлары белән тәэмин итәргә, 2021 елның 1 гыйнварына кадәр аларны Яңа ел бүләкләре комплектына кертүне тәэмин итәргә;

пассажирларны автобус транспорты белән рөхсәтсез җибәрү урыннарын бетерү буенча тулы чаралар күрергә;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссия эше кысаларында халыкның яктылыкны кире кайтару элементларын куллануны популярлаштыру мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә;

ярты елга кимендә бер тапкыр, авыл җирлекләре башлыкларын һәм балалар белем бирү оешмалары директорларын, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге

автомобиль юлларын баланста тотучыларны чакырып, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышын үткәрергә;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларында, беренче чиратта, белем бирү оешмалары, җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары, автобус тукталышлары янында, автомобиль юлларының куркыныч авария участокларында һәм халык күпләп җыела торган урыннарда ясалма яктырткыч урнаштыруны дәвам итәргә;

юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларына һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча башка чараларга (ясалма тигезсезлекләрне, җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарын һәм яктырту җайланмаларын төзекләндерү, киртәләр урнаштыру һәм светофор белән җайга салуны оештыру) чыгымнарны җирле бюджет акчасыннан күздә тотарга;

муниципаль парковкаларны оештырганда аларның урнашу урыннарын һәм юл хәрәкәтен оештыру схемаларын Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсе белән килештерергә;

төзелеп, реконструкцияләп, капиталь ремонт яки ремонт ясалып беткәннән соң кулланышка кертелә торган автомобиль юллары һәм юл корылмалары участокларының юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килү-килмәүне алдан бәяләүне оештырганда, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына караган Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең вазыйфаи затларын тиешле комиссияләре составына килештерү буенча кертергә;

автомобиль юллары участокларына реконструкция яки ремонт ясала торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш полосаларын, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллануга юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашырырга;

каршы килә торган хәрәкәт полосасына чыгу аркасында барлыкка килә торган һәлак булучылары булган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү өчен, шулай ук җәяүлеләрнең юлны чыгу өчен каралмаган урыннарда машиналар йөри торган өлештән чыгуын чикләү өчен барьер тибындагы металл киртәләр, трослы һәм җәяүләр киртәләрен куюны дәвам итәргә;

автомобиль юллары участокларында, транспорт агымының туктаусыз хәрәкәтен, шул исәптән машина юлларыннан транспорт чараларына үтәргә комачаулый торган объектларны алуны тәэмин итеп, һәлак булучылары булган юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерү буенча чаралар күрергә;

юл сервисы объектларының юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килмәвен билгеләгәндә объектлар милекчеләренә җитешсезлекләрне бетерүне йөкләргә, таләп үтәлмәгәндә, мәгълүматны прокуратура органнарына җибәрергә;

юл хәрәкәте иминлеге буенча комиссияләр үткәргәндә машина йөртүчеләргә транспорт чаралары белән идарә итәргә рөхсәт итүне һәм аларның район автотранспорт предприятиеләрендә техник торышын тикшерүдә тотуны оештыру мәсьәләләрен җентекләп өйрәнүне башлап җибәрергә;

халыкны транспорт белән өзлексез тәэмин итү максатларында автобусларны техник карау пунктларының җитәрлек булуын һәм территориаль яктан файдалана алырлык булуын анализларга.

16. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында» 2018 ел, 17 декабрь,1149 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

17. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин